**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 8 апрель № 232

г. Казань

«Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0»
автоном коммерциячел булмаган оешмасын
гамәлгә кую турында

Татарстан Республикасында сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны беркетү максатларында, Татарстан Республикасы Президенытының «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясе турында» 2012 ел, 9 октябрь, ПУ-862 нче Указы белән расланган «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 3 декабрь, 943 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасын (алга таба – Автоном оешма) гамәлгә куярга.

2. Автоном оешманың бу карарга теркәлгән уставын расларга.

3. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Автоном оешманы законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

Автоном оешманы гамәлгә куюга бәйле булган башка чаралар үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына Автоном оешмага аның эшчәнлегендә һәртөрле ярдәм күрсәтергә, ә Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\232.doc